ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03 март 2021ел № 1444

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча комиссия төзү турында

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү максатында, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча комиссия төзергә.

2. Расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча комиссия турында нигезләмәне 1 нче кушымтада каралганча;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча комиссия составын 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 3 мартындагы
1444 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына
мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча комиссия турында
нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча комиссия (алга таба – комиссия) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (алга таба – КУЭ субъектлары) мөлкәти ярдәм күрсәтү максатында оештырылган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законга, Шәһәр Советының 2007 елның 25/5 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Комиссия үз эшчәнлеген аның әгъзаларының тигез хокуклылыгы, карарлар кабул итү коллегиальлеге һәм хәбәрдарлык принципларында гамәлгә ашыра.

4. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

1) «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру кысаларында КУЭ субъектларына, КУЭ субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, шәхси эшмәкәр булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга (алга таба – махсус салым режимын кулланучы физик затларга) мөлкәти ярдәм күрсәтү;

2) формалаштыру, раслау, алып бару һәм мәҗбүри бастырып чыгару тәртибе Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану, идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турында нигезләмәнең 19 бүлеге белән расланган, өченче затлар хокукларыннан (хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәти хокукларыннан тыш) азат булган һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларның муниципаль мөлкәт исемлеген (алга таба – Исемлек) формалаштыру һәм киңәйтү өчен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә файдаланылмый торган, нәтиҗәсез файдаланыла торган яки билгеләнеше буенча файдаланылмый торган мөлкәт хисабына өстәмә чыганаклар эзләү;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә КУЭ субъектларына, КУЭ субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга, махсус салым режимын кулланучы физик затларга мөлкәти ярдәм күрсәтүне оештыруга бердәм якын килүне тәэмин итү.

5. Комиссиянең төп функцияләре булып тора:

1) мөлкәти ярдәм күрсәтүнең гамәлдәге механизмнарына анализ ясау һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү;

2) Исемлеккә кертү мөмкинлеген карау өчен файдаланылмый торган, нәтиҗәсез файдаланыла торган яки билгеләнеше буенча файдаланылмый торган мөлкәтне ачыклау максатында муниципаль мөлкәт реестрына анализ ясау;

3) Яр Чаллы шәһәренең муниципаль предприятиеләреннән һәм муниципаль учреждениеләреннән, җәмәгатьчелек вәкилләреннән, КУЭ субъектларыннан, КУЭ субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалардан, махсус салым режимын кулланучы физик затлардан Исемлекне тулыландыру турында кергән тәкъдимнәрне карап тикшерү;

4) муниципаль учреждениеләр һәм муниципаль предприятиеләр тарафыннан бирелгән күчемсез милек объектлары турындагы мәгълүматларны карап тикшерү һәм анализлау;

5) Исемлеккә объектлар өстәү мәсьәләсе буенча мөлкәти ярдәм күрсәтү буенча рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр эшләү;

6) КУЭ субъектлары, махсус салым режимын кулланучы һәм социаль әһәмияткә ия эшчәнлек төрләре, муниципаль программалар (ярдәмче программалар) белән билгеләнгән башка өстенлекле эшчәнлек төрләре белән шөгыльләнүче физик затлар эшчәнлегенә анализ ясау;

7) мәгълүмати һәм консультацион ярдәм күрсәтү;

8) мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча региональ, федераль хакимият органнары, шулай ук «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча федераль корпорация» акционерлык җәмгыяте белән үзара эшчәнлек.

## 2 бүлек. Комиссиянең вәкаләтләре һәм эш тәртибе

6. Аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Комиссия хокуклы:

1) үз утырышларында комиссия компетенциясе нигезендә мәсьәләләрне карап тикшерергә, тиешле карарлар кабул итәргә;

2) Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының тармак һәм территориаль органнарында, муниципаль предприятиеләрдә һәм учреждениеләрдә, иҗтимагый оешмаларда үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

3) КУЭ субъектларын, махсус салым режимын кулланучы физик затларны, фәнни һәм иҗтимагый оешмаларны һәм комиссия әгъзалары булмаган башка оешмаларны комиссия утырышларында катнашуга җәлеп итәргә;

4) КУЭ субъектларының, КУЭ субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларның, махсус салым режимын кулланучы физик затларның муниципаль мөлкәтне мөлкәти ярдәм күрсәтү процессына җәлеп итү буенча тәкъдимнәрен карап тикшерергә;

5) Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнарына, муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча рекомендацияләр бирергә;

6) материалларны «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырып, үз эшчәнлеге турында хәбәр итәргә, шул исәптән эшче төркемнең булачак утырышлары турында мәгълүмат урнаштырырга.

7. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кимендә елга бер тапкыр үткәрелә.

8. Комиссия рәис, рәис урынбасары, секретарь һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

9. Комиссиянең сан ягыннан һәм персональ составы Башкарма комитет карары белән раслана. Комиссиянең сан ягыннан составы тугыз кешедән дә ким була алмый.

10. Комиссия белән комиссия эшен оештыручы рәис җитәкчелек итә.

11. Комиссия әгъзалары вәкаләтле:

1) комиссия утырышларын әзерләүдә катнашырга;

2) комиссия рәисенә комиссия утырышының көн тәртибе буенча тәкъдимнәр кертергә;

3) комиссия рәисенә комиссия утырышын кичектерү турында тәкъдимнәр кертергә;

4) комиссия утырышларында катнашырга;

5) комиссия каравына чыгарылган мәсьәләләр турында фикер алышуда катнашырга;

6) карап тикшерелә торган материаллар буенча комиссия тарафыннан карарлар кабул иткәндә тавыш бирүдә катнашырга.

12. Комиссия рәисе комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссия бурычлары нигезендә аның эшен оештыра, комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, үзенә йөкләнгән бурычларны үтәүне тәэмин итә;

2) комиссия утырышын үткәрү урынын, вакытын һәм көн тәртибен билгели;

3) комиссия утырышларында рәислек итә;

4) комиссия утырышларында кабул ителгән карарларны имзалый.

13. Комиссия рәисе урынбасары комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссия рәисе боерыкларын үти;

2) комиссия рәисе булмаганда аның вазыйфаларын башкара.

14. Комиссия секретаре комиссия әгъзасы вәкаләтләреннән файдалана, шулай ук:

1) комиссиянең эш кәгазьләрен алып бара;

2) комиссия утырышларына материаллар, шулай ук карарлар проектларын әзерләүне оештыра;

3) комиссия әгъзаларына комиссиянең чираттагы утырышын үткәрү урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле белешмә-мәгълүмати материаллар белән тәэмин итә;

4) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

5) комиссия рәисе һәм аның урынбасары боерыкларын үти.

15. Көн тәртибе, комиссия утырышын үткәрү урыны турында мәгълүматлар һәм комиссия каравына чыгарылган мәсьәләләрне карап тикшерү өчен кирәкле материаллар, аны үткәргәнче биш календарь көннән дә соңга калмый, комиссия әгъзаларына җиткерелә.

16. Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә өчтән ике өлеше катнашса, комиссия утырышы тулы хокуклы була.

17. Комиссия карары, ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашучы комиссия әгъзалары санының күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

18. Комиссия карары комиссия утырышында рәислек итүче һәм җаваплы секретарь тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2021 елның 3 мартындагы
1444 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына
мөлкәти ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча
комиссия составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Салахов Фәрид Шавкат улы | комиссия рәисе,<br>Башкарма комитет Җитәкчесе |
| 2. | Гыйззәтуллин Ленар Рәис улы | комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы |
| 3. | Шахматова Светлана Солтан кызы | комиссия секретаре, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең исәпкә алу һәм мөлкәт белән идарә итү бүлеге башлыгы |
| комиссия әгъзалары: | | |
| 4. | Әхмәтҗанов Ленар Илдар улы | Башкарма комитетның хокук идарәсе башлыгы |
| 5. | Гайнуллин Илдар Наил улы | Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы |
| 6. | Кәрамиев Румил Рәүф улы | Башкарма комитетның мәдәният идарәсе башлыгы |
| 7. | Кропотова Наталия Анатольевна | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 8. | Мәхмүтов Айзат Гамир улы | Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |
| 9. | Мулюкова Светлана Рафаиль кызы | Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы |
| 10. | Насрединов Роман Мансур улы | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе башлыгы |
| 11. | Хуҗин Рөстәм Нияз улы | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе башлыгы. |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева